**Мәктәп тарихы.**

20 нче еллар. Авылыбызнњ урта бер җирендә тирә-якка даны таралган Шиһабетдин хәзрәтнең зур мәдрәсәсе була. Революциядән сон, мәдрәсәне мәктәп итеп узгәртәләр. Бу мәдрәсәдә Гыймадиев Бәдретдин, Хәмзин Салих, фәндә зур хезмәтләре белән урын алган аталы-уллы Мөштәриләр дә укыткан.

1927 нче ел. Мәктәп җидееллык булып узгәртелә.

1934 нче ел. Беренче чыгарылыш була.

1941-1945 еллар. Бу елларда да мәктәп тулы көченә эшләгән.

1946-1947 еллар. Мәктәптә 186 укучы укыган. Чыгарылыш сыйныфында 11 укучы булган.

1961 нче ел. Мәктәп сигезьеллык булып үзгәртелгән.

1961-1972 нче еллар. Мәктәпне РСФСРнын, Мәгариф Отличнигы Ибәтуллин Мөнир Нәбиулла улы житәкләгән. Бер катлы яңа бина сафка баса. Мәктәпнең материаль - техник базасы ныгый. Үзәктән ягу системасына күчерелә.

1982 нче ел. Урта мәктәп булып эшли башлый. 1974-1992 нче елларда мәктәп белән РСФСР нын Мәгариф Отличнигы Гыйльметдинов Ирек Габдулла улы җитәкчелек итә. Бу елларда мәктәптә күп кенә төзелешләр алып барыла. Мәктәп бинасына өстәмә кабинетлар өчен янкорма, подвал, ашханә төзелә. Намуслы хезмәтләре өчен Ибәтуллина Зәйтүнә Гыйльмулла кызы һәм Гыйльметдинова Фәния Малик кызына РСФСР нын, Мәгариф Отличнигы значогы бирелә.

1997 нче ел. Мәктәпкә унберьеллык урта гомуми белем бирү мәктәбе статусы бирелә.

2008 нче ел. Төп гомуми белем биру мәктәбе итеп узгәртелә. Шул ук елда яңа бина төзелә һәм укулар шунда дәвам ителә.